ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июль 2018 ел № 4226

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, «Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 31 маддәсе, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2012 елның 24 июлендәге 258 нче приказы белән расланган Авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасына автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итү өчен махсус рөхсәт бирү тәртибе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 нче, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 нче, 2017 елның 8 февралендәге 588 нче, 2017 елның 3 маендагы 2747 нче, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 нче, 2018 елның 18 июлендәге 4000 нче карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«24. Авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасының Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында хәрәкәт итүе өчен махсус рөхсәт бирү.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин